ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ с. Верхний Услон КАРАР ______________

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Югары Ослан муниципаль районы хакимияте органнарының физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү максатларында һәм “Реклама турында” 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан административ хезмәт күрсәтүләрнең регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы белән, Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 31 мартындагы 773 номерлы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигына әлеге карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын үтәүне тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хакимзянов

Минһаҗев З.З
2 нөсхәдә